**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «06» сентябреннән № 36-297

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Коррупциячел хокук бозулар кылган өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында» 2014 елның 11 апрелендәге 33-190 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2014 елның 11 апрелендәге 33-190 номерлы карары белән расланган коррупциячел хокук бозулар кылган өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 12 февралендәге 6-38 номерлы, 2021 елның 26 февралендәге 6-38 номерлы карарлары редакциясендә) (алга таба Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.4 пунктындагы 2 абзацына түбәндәге сүзләрне өстәргә:
«, Федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш».».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru , «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек итү комиссиясе рәисенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов